ГЛАВА СТАРОКАШИРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
05 ноябрь 2025 ел

КАРАР
№ 3

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылында гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы:

1.2025 елның 14 ноябренә 08 сәгать 30 мин. Зиннәт Хәсәнов урамы,11а нчы йорт адресы буенча урнашкан торак йортта гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнарны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:«2026 елда Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан, тыл ветераннарыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән хэм мобилизацияләнгәннәр, аларның гаилә членнарыннан тыш, 3500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; (ЗИЛ-131 автомобиле: ягулык-майлау материаллары, запас часть);

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту ; (кардан чистарту,чуп үләннәрен чабу, юлларны грейдировкалау, МТЗ-82: ягулык-майлау материаллары, түләү, запас часть);

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO) урнаштырырга. TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 7 көн эчендә.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Дәүләтҗанов